# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 22 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^3$ пунктлар өстәргә:

"$6^1$) гомуми файдаланудагы региональ әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкаларны (парковка урыннарын) оештыру һәм алардан түләүле нигездә файдалану турында һәм мондый файдалануны туктату турында карарлар кабул итү;

$6^2$) гомуми файдаланудагы региональ әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкаларны (парковка урыннарын) оештыру һәм алардан, шул исәптән түләүле нигездә, файдалану тәртибен билгеләү;

$6^3$) гомуми файдаланудагы региональ әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә файдалану өчен түләү күләмен билгеләү;";

б) 7 пунктта "йөрү" сүзеннән соң ", гомуми файдаланудагы региональ әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә файдалану" сүзләрен өстәргә;

2) 12 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) региональ әһәмиятле автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өчен региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру;";

3) 13 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) җирле әһәмиятле автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өчен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;";

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ – $4^3$ пунктлар өстәргә:

"$4^1$) гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкаларны (парковка урыннарын) оештыру һәм алардан түләүле нигездә файдалану турында һәм мондый файдалануны туктату турында карарлар кабул итү;

$4^2$) гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкаларны (парковка урыннарын) оештыру һәм алардан, шул исәптән түләүле нигездә, файдалану тәртибен билгеләү;

$4^3$) гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә файдалану өчен түләү күләмен билгеләү;";

в) 5 пунктта "йөрү" сүзеннән соң ", гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә файдалану" сүзләрен өстәргә;

4) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $13^1$ статья өстәргә:

"$13^1$ статья. **Автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә региональ дәүләт күзәтчелеге, муниципаль контроль**

1. Автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә региональ дәүләт күзәтчелеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле әһәмиятле автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.";

5) 15 статьяның 2 өлешендә:

а) беренче абзацта ", капиталь ремонтлауга" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 пунктта ", реконструкцияләү яисә капиталь ремонтлау" сүзләрен "яисә реконструкцияләү" сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта ", реконструкцияләү яисә капиталь ремонтлау" сүзләрен "яисә реконструкцияләү" сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 пунктта ", реконструкцияләү яисә капиталь ремонтлау" сүзләрен "яисә реконструкцияләү" сүзләренә алмаштырырга;

6) 16 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Автомобиль юлларын тоту автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү, шулай ук юл хәрәкәтен, шул исәптән автомобиль юлларында транспорт чараларының эзлексез хәрәкәтен һәм мондый хәрәкәт өчен имин шартлар булдыру юлы белән, оештыру максатларында техник регламентлар таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла. Автомобиль юлларын ремонтлау автомобиль юлларында транспорт чараларының эзлексез хәрәкәтен һәм мондый хәрәкәт өчен имин шартлар булдыру, шулай ук автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү максатларында техник регламентлар таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.";

7) 17 статьяда:

а) исемендә "инженерлык коммуникацияләрен салу һәм яңадан урнаштыру" сүзләрен "инженерлык коммуникацияләрен салу, яңадан урнаштыру, күчерү, аларны эксплуатацияләү" сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә "инженерлык коммуникацияләрен салу һәм яңадан урнаштыру" сүзләрен "инженерлык коммуникацияләрен салу, яңадан урнаштыру, күчерү, аларны эксплуатацияләү" сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә "салган һәм яңадан урнаштырган очракта" сүзләрен "салган, күчергән яисә яңадан урнаштырган очракта" сүзләренә алмаштырырга, "инженерлык коммуникацияләрен салу һәм яңадан урнаштыру планлаштырыла торган" сүзләрен "инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яисә яңадан урнаштыру планлаштырыла торган" сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлештә "салган яисә яңадан урнаштырган очракта" сүзләрен "салган, күчергән яисә яңадан урнаштырган очракта" сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә "проектлау, салу һәм яңадан урнаштыру буенча башкарылган эшләрне" сүзләрен "проектлау, салу, күчерү яисә яңадан урнаштыру буенча башкарылган эшләрне" сүзләренә алмаштырырга;

8) 18 статьяда:

а) 1 өлештә ", капиталь ремонтлау" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә "ремонтлау" сүзен "капиталь ремонтлау, ремонтлау" сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә "ремонтлау" сүзен "капиталь ремонтлау, ремонтлау" сүзләренә алмаштырырга;

9) 20 статьяда:

а) 5 өлештә ", капиталь ремонтлау" сүзләрен 2 урында төшереп калдырырга;

б) 6 өлештә ", капиталь ремонтлау" сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 25 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендә юл сервисы объектларын урнаштыру, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре шул объектларны урнаштыру өчен гражданнарга яисә юридик затларга бирелергә мөмкин.

Автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендә юл сервисы объектларын урнаштыру, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата, Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, граждан законнарында һәм җир законнарында билгеләнгән тәртиптә хосусый сервитутлар билгеләү рөхсәт ителә. Региональ, җирле әһәмиятле автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендә юл сервисы объектларын урнаштыру, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен җир кишәрлекләре тиешенчә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы, җирле үзидарә органнары тарафыннан законнар нигезендә бирелә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ һәм $4^2$ өлешләр өстәргә:

"$4^1$. Гражданнарның яисә юридик затларның юл сервисы объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, аларны эксплуатацияләү, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү максатларында хосусый сервитут шартларында, инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү, яңадан урнаштыру, аларны эксплуатацияләү максатларында гавами сервитут шартларында автомобиль юлларының (хосусый автомобиль юлларыннан тыш) бүленгән полосасы чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдалануы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителә.

$4^2$. Хосусый автомобиль юлларының бүленгән полосалары чикләрендәге җир кишәрлекләренә карата граждан законнары һәм җир законнары нигезендә сервитутлар билгеләнергә мөмкин.";

11) 27 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Региональ, җирле әһәмиятле автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 13 гыйнвары
№ 3-ТРЗ